РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

23.10.2015 ел №10

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

2016 елга Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
бюджеты проектын төзү һәм раслау
үзенчәлекләре турында

2015 елның 30 сентябрендәге 273-ФЗ номерлы «2016 елга Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары проектларын төзү һәм раслау үзенчәлекләре, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында» Федераль законның 3 статьясының үз көчен югалтуын тану турында» Федераль закон, Чирмешән муниципаль районы Уставы нигезендә, Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 2016 елның 1 гыйнварына кадәр Советның 2013 елның 26 ноябрендәге 192 номерлы карары белән (2014 елның 20 октябрендәге 214 номерлы үзгәрешләр белән) расланган «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында бюджет процессы турында нигезләмәләр» нигезләмәләренең план чорына карата Чирмешән муниципаль районы бюджеты проектын (Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджеты турында карар проекты) төзү һәм раслауга карата гамәлдә булуын, Чирмешән муниципаль районы Советына күрсәтелгән проект белән бер үк вакытта план чорына документлар һәм материаллар тапшыруны туктатып торырга (Чирмешән муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше фаразыннан тыш, бюджет сәясәте һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләреннән тыш).

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының авыл җирлекләре башлыкларына шундый ук карарлар кабул итәргә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль район
башлыгы, Совет рәисе Ф.М. Дәүләтшин